**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКТАНЫШБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
423740, Актанышбаш авылы, Мәктәп ур.,
19 нче йорт. Тел 3-44-39
Email: akt.aktbash@yandex.ru

**АКТАНЫШБАШСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
423740, д. Актанышбаш, ул. Школьная, дом 19. Тел 3-44-39
Email: akt.aktbash@yandex.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«27» гыйнвар 2026 года** **№ 7**

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гомуми тыңлаулар үткәрү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24,28 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә, Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге Уставы белән Актаныш муниципаль районының Актанышбаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Актанышбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча 2026 елның 3 февраленә гомуми тыңлаулар билгеләргә.

2. Гомуми тыңлауларны үткәрү урыны итеп түбәндәге урыннарны билгеләргә:
- Актанышбаш авылы, Актанышбаш мәдәният йорты бинасы, адрес буенча урнашкан: Актанышбаш авылы, Мәктәп урамы, 21 нче йорт, үткәрү вакыты 10:00 сәгать;
- Чөгәнә авылы, Чөгәнә мәдәният йорты бинасы, адрес буенча урнашкан: Чөгәнә авылы, Колхоз урамы, 47 нче йорт, үткәрү вакыты 12:00 сәгать;
- Ирмәш авылы, йорт каршында, адрес буенча урнашкан: Ирмәш авылы, Үзәк урамы, 15 нче йорт, үткәрү вакыты 14:00 сәгать;
- Әҗәкул авылы, йорт каршында, адрес буенча урнашкан: Әҗәкул авылы, Үзәк урамы, 3 нче йорт, үткәрү вакыты 16:00 сәгать.

3. Гомуми тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Актанышбаш авылы, Мәктәп урамы, 19 йорт.

4. Әлеге карарны "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Рес-публикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сай-тындагы "авыл җирлекләре" бүлегендә: http:/aktanysh.tatarstan.ru.

5. Әлеге карар халыкка игълан ителгән мизгелдән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Маликов Г.Р.**